КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 сентябрь г.Казань № 825

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ай саен бирелә торган гомерлек дәүләт пособиеләрен раслау турында» 2005 ел, 10 июнь, 262 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ай саен бирелә торган гомерлек дәүләт пособиеләрен раслау турында» 2005 ел, 10 июнь, 262 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 11 июль, 495 нче; 2012 ел, 15 июнь, 517 нче; 2013 ел, 18 март, 167 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бу карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

4 нче пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Күренекле нәтиҗәләргә ирешкән Татарстан Республикасы спортчыларына ай саен бирелә торган гомерлек дәүләт пособиеләрен билгеләү һәм түләү тәртибендә:

2 нче пунктка «билгеләнә» сүзе алдына «Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаганда» сүзләрен өстәргә;

3 нче пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин